Карар № 10

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советы

«06» февраль 2026 ел Олы Мәңгәр авылы

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советының 2019 елның 3 октябрендәге 108 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2025 елның 28 ноябрендәге 425-ФЗ номерлы "Россия Федерациясенең Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең закон актларын (аерым положениеләрен) гамәлдән чыгару турында" Федераль закон нигезендә, Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советының 2019 елның 3 октябрендәге 108 номерлы «Җир салымы турында» карарына (20.01.2020 ел № 125, 30.10.2020 ел № 9, 30.01.2024 ел № 90, 24.10.2024 ел №102 29.07.2025 № 123 үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

**1.1. 4 пунктның 4.3 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:**

«4.3. Әгәр әлеге пунктта башкасы каралмаган булса, салым, салым түләүче оешмалар тарафыннан узган салым чорыннан соң килә торган елның 28 мартыннан да соңга калмыйча түләнергә тиеш, салым буенча аванс түләүләре салым түләүче оешмалар тарафыннан узган хисап чорыннан соң килә торган икенче айның 28 нче числосыннан да соңга калмыйча түләнергә тиеш»;

**1.2. 4 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4.4 пунктчасы өстәргә:**

«4.4. Салым (салым буенча аванс түләве), узган салым (хисап) чорлары өчен салым (салым буенча аванс түләве) суммасын исәпләүгә (яңадан исәпләүгә) китерә торган мәгълүматлар нигезендә исәпләнгән, оешма-салым түләүчеләр тарафыннан тиешле чор өчен салым органы тарафыннан исәпләнгән салым (салым буенча аванс түләве) суммасы турында хәбәр формалаштырылган айдан соңгы айның 28-еннән соңга калмыйча түләнергә тиеш.»

2. Әлеге карар 2027 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертелә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Олы Мәңгәр авыл җирлеге
башлыгы Филатова Ф.Ф.